ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 21 октябре № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылында гражданнар җыены

КАРАР:

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавел авыл җирлегенең Андреевка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасында укучы студентлардан; контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм бензотриммерларга чапкыч өчен запас частьләр сатып алу, кыргый агачларны кисү, балалар мәйданчыгында таган, эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3."Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында "бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru/, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында:https://novosheshminsk.tatar.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Андреевка авылы, Үзәк урамы, 5 нче йорт янындагы мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Петропавел авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы Д.С. Никитин

СОВЕТ ПЕТРОПАВЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ